**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «27» февраленнән № 49

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемаларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы һәм «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының

Яңа Чишмә һәм Ленино авыл җирлекләре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын килештерү турында» 2017 елның 31 октябрендәге 534 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru , «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «27» февраленнән
49 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Стационар булмаган сәүдә объекты урнашкан урын | Сатыла торган товарлар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектының тибы | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | ГХАТ бинасы каршындагы мәйдан | Азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар | Палатка | Сезонлы |
| 2 | Ленин урамындагы сквер | Азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар | Палатка | Сезонлы |
| 3 | Мәдәният һәм ял паркы, Ленин урамы | Азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар | Палатка | Сезонлы |
| 4 | РМЙ янындагы парк | Азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар | Палатка | Сезонлы |